**Аяз булсын күгебез**

1) Сихри аяз таңнар,
Җылы якты язлар,
Дәшә безне бөек эшләргә.
Омтылабыз алга,
Ачышлар ясарга,
Илебезне данга кумергә.

Кушымта:

Җырлыйк әйдә бергә,
Кушылыгыз сез дә,
Яңгырасын бәхет җырлары.
Очсын киләчәккә,
Мәңге сүрелмичә,
Балачакнын шат авазлары.

2) Бәхетле балачак,
Тели куңел хәрчак:
Аяз булсын, диеп кугебез.
Тусын жырлы жирдә,
Балачак илендә:
Тыныч булсын дөньяларыбыз.